ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

07.05.2020 с.Старое Дрожжаное № 110

2020 елның апрель-июнь айларында муниципаль мөлкәтне арендалау килешмәләре буенча аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты БОЕРЫК БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне (алга таба - муниципаль мөлкәт) арендалау шартнамәләре буенча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мөрәҗәгать иткән көннән алып җиде эш көне эчендә муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен кичектерүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү, 2020 елның апрель - июнендә мондый арендаторлар тарафыннан тәкъдим ителгән срокка, 2021 елның гыйнварыннан да соңга калмыйча, кичектереп торылган аренда түләүләрен түләү срогы башлангач;

б) әлеге боерык үз көченә кергән көннән алып өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен әлеге пунктның «а» пунктчасы нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыру.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору арендаторларга - кече һәм урта эшкуарлык субъектларының Бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирелә, алар Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлләр режимы кертелгән көнгә кадәр муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча алдагы чор өчен аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмаса);

әлеге боерыкның 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә төзелә торган өстәмә килешүләр 2020 елның апрель-июнь айлары өчен аренда түләвен кичектереп торуны һәм аны 2020 һәм (яки) 2021 елларда аренда килешүендә каралган срокларда тигез өлешләрдә түләүне, шулай ук аренда түләүләре суммасын бер тапкыр түләүне күздә тотарга тиеш.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыгарга тиеш.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И. Р. Измайловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов